
Муса Җәлил музее
Музей Мусы Джалиля

Себер тракты тарихы музее
Музей истории Сибирского тракта





МУСА ҖӘЛИЛ МУЗЕЕ

Карадуган мәктәбенең пионер дружинасы 1955 елдан Муса Җәлил исемен йөртте. Укучылар шагыйрьнең тормыш юлын, үлемсез иҗатын, батырлыгын өйрәнделәр, төрле кичәләр, очрашулар үткәрделәр, стендлар, альбомнар төзеделәр.

1975 елда Җәлил эзләре буйлап Оренбург өлкәсенә сәяхәт ясалды. Балалар шагыйрьнең туган авылы Мостафада булдылар, Муса Җәлилнең авылдашлары, туганнары белән очраштылар, истәлекләрен язып алдылар, әнисенең кабереннән изге туфрак алып кайттылар. Яшь эзтабарлар Мостафа авылыннан Оренбург каласына кадәр җәяүләп барып, Оренбургта Муса Җәлил белән бергә укыган, эшләгән Фатих Солтанов, Рокыя Рәхимова, Гөлсем Хәсәнова белән очраштылар. Оренбургтагы төп очрашу, билгеле, Муса Җәлилнең сеңлесе Хәдичә Җәлилова белән булды. Укучылар бу сәяхәттән бай материал туплап кайтты.

Муса Җәлилнең тууына 70 ел тулган көндә – 1976 елның

МУЗЕЙ МУСЫ ДЖАЛИЛЯ

В 1955 году пионерская дружина Карадуванской школы стала носить имя Мусы Джалиля. Все это время ученики изучали жизнь, бессмертное творчество, героизм поэта, проводили разного рода вечера, встречи, делали стенды, альбомы.

В 1975 году пионеры по следам поэта-героя отправились в Оренбургскую область: были в Мустафино, родной деревне героя, встретились с его односельчанами и родственниками, собрали и записали воспоминания, привезли горсть земли со священной могилы матери Джалиля.

Из Мустафино молодые следопыты пешком добрались до Оренбурга, встретились с людьми, которые учились и работали с Мусой: Фатихом Султановым, Рокией Рахимовой, Гульсум Хасановой. Главная встреча, конечно, была с младшей сестрой Мусы Джалиля – Хадичей Залиловой. Из путешествия дети вернулись с богатым материалом и глубокими впечатлениями.



15 февралендә мәктәптә музей ачылды. Укучылар сәяхәт-эзләнүләрне дәвам итеп, 1976 елда Новгород өлкәсенә, «Отвага» газетасы редакциясе эшләгән, Муса Җәлил әсирлеккә төшкән урынга – «Үлем үзәне»нә сәяхәт кылдылар, кайтышлый Мәскәүдә Мусаның хатыны Әминә ханым, кызы Чулпан белән очраштылар. Шулай ук Җәлилнең көрәштәше Гайнан Кормаш укыган һәм эшләгән Мари Иленең Бәрәңге һәм Куян авылларына, Татарстандагы Муса Җәлил исеме белән бәйле урыннарга, Одесса каласына бардылар, «Муса Җәлил» теплоходында булдылар.

Муса Җәлил музеена 1979 елда ук «Мәктәп музее» статусы бирелде һәм ул мәктәп музейларының Бөтенсоюз каталогына кертелде. СССРның төрле почмаклары белән хатлар алышынды, Камчатка, Украина, Эстония, Урта Азия республикаларыннан, хәтта чит ил – ГДРдан да хатлар килде.

Музей эшендә «Кызыл ромашка» дигән укучылар оешмасы да катнаша. Һәр елның февраль аенда Җәлил көннәре уза, шигырь, җыр конкурслары, Җәлил призына хоккей ярышлары оештырыла. Җәлил

15 февраля 1976 года – в день 70-й годовщины со дня рождения поэта – в школе был открыт музей Мусы Джалиля. Ученики, продолжив поиски, в 1976 году добрались до Новгорода, до «Долины смерти», где работала редакция газеты «Отвага» и где Муса Джалиль попал в плен. Возвращаясь, навестили жену и дочь героя – Амину ханум и Чулпан. Были в деревнях Параньга и Куяново Марийской республики, на родине сподвижника Джалиля – Гайнана Курмашева. Ездили в Одессу, на теплоходе «Муса Джалиль» вышли в открытое море, а также побывали в других местах Татарстана, связанных с именем поэта-героя.

Уже в 1979 году музею Мусы Джалиля присвоили статус школьного музея и включили во Всесоюзный каталог школьных музеев. Началась переписка со всеми уголками СССР, будь то Камчатка, Украина, Эстония, республики Средней Азии. Письма шли даже за границу – в частности, в ГДР.

Организация школьников «Красная ромашка» – активно участвует в деятельности музея. Ежегодно в феврале проводятся Дни Джалиля – конкурсы стихотворений, песен,

туган көндә «Кызыл ромашка» оешмасына яңа әгъзалар кабул ителә. Әүвәлрәк әлеге тантанага Җәлилне белгән, аның белән эшләгән яки көрәшкән кешеләр чакырыла иде. Җәлилнең көрәштәшләре Рушад Хисаметдинов, Фәрит Солтанбәков, туганы Таһир Корбанов, улы Альберт Җәлилов, шагыйрьнең иҗатташ дуслары, замандашлары Усман Әлмиев, Фатих Исхаков, Бакый Урманче, шулай ук Җәлилнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүче галим, язучылардан Рафаэль Мостафин, Нил Юзиев, Исхак Зәбиров, Фоат Мостафин, «Моңлы бер җыр» спектаклендә Муса ролен башкарган Ринат Таҗетдинов, шагыйрьнең әнисе ролендә уйнаган Рәшидә Җиһаншина, пьесаның авторы, халык язучысы драматург Туфан Миңнуллин, халык язучылары һәм шагыйрьләре Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Равил Фәйзуллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Роберт Миңнуллин, композитор Фасил Әхмәтов һ.б. музейда кунакта булдылар. Хәзер андый очрашуларга Татарстанның Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе лауреатлары чакырыла. Музейдагы очрашуларга

а также хоккейный турнир на приз Джалиля. В день рождения поэта в «Красную ромашку» принимаются новые члены. Ранее в Дни Джалиля приезжали люди, работавшие, воевавшие вместе с ним, или просто знавшие его. Скажем, соратники Рушад Хисамутдинов, Фарит Султанбеков, родственник Мусы Тагир Курбанов, сын Мусы Альберт Залилов, друзья, коллеги, современники – Усман Альмеев, Фатих Исхаков, Баки Урманче, ученые и писатели, изучающие жизнь и творчество Джалиля – Рафаэль Мустафин, Нил Юзиев, Исхак Забиров, Фоат Мустафин, исполнитель роля Мусы Джалиля в спектакле «Моңлы бер җыр» («У совести вариантов нет») Ринат Тазетдинов, исполнительница роли матери в том же спектакле Рашида Зиганшина, автор пьесы, народный писатель Татарстана, драматург Туфан Миннуллин, татарские поэты и писатели Ильдар Юзеев, Шаукат Галиев, Равиль Файзуллин, Мухаммет Магдеев, Роберт Миннуллин, композитор Фасиль Ахметов и другие. Последнее время приглашаются лауреаты Республиканской премии имени Мусы Джалиля. На такие встречи приезжают



күрше-тирә мәктәплләрдән дә укучылар күп килә.

Җәлилнең батырлыгын, иҗатын пропагандалаудагы эшчәнлеге өчен 1990 елда музейга Татарстан Республикасының Муса Җәлил премиясе бирелде.

Татарның каһарман улы, батырлыгы легендага әйләнгән Муса Җәлил яшь буында милли аң тәрбияләүдә мөһим урын били һәм биләячәк. Бу юнәлештә музей нәтиҗәле эш башкара һәм ул киләчәктә дә шулай булыр.

учащиеся многих окрестных школ.

За пропаганду героизма и творчества Джалиля музей в 1990 году был награжден Республиканской премией Мусы Джалиля.

Жизнь и героический подвиг сына татарского народа, имя которого давно стало легендой, были и остаются примером для подражания, а также важным фактором развития и воспитания национального самосознания подрастающего поколения. Наш музей всячески способствует этому.



Бакый Зыятдинов, музей директоры

Баки Зиятдинов, директор музея





Оештырылуының 30 еллыгына Муса Җәлил музее заманча итеп яңартылды

Музей Мусы Джалиля к 30-летию со дня основания был отреставрирован и обновлен

Музейда әдәбият, сәнгать әһелләре еш була.
Шагыйрьләр Мөхәммәт Мирза (сулда) һәм Ркаил Зәйдулла

Музей часто посещают деятели литературы и искусства.
Поэты Мухаммат Мирза (слева) и Ркаил Зайдулла








Экспозицияләрнең гомуми күренеше

Общий вид экспозиций



تاتار ئەدەبیاتی تاریخی.

برنچی جیلد

بۇرنغی دەور.

ئوچنچی بولەك

М.Җәлил автографы куелган китап бите. 1923 ел

Страница книги с автографом М.Джалиля. 1923 г.

Шагыйрьнең балачагын яктырткан экспозиция

Экспозиция, посвященная детству поэта








Музейда Муса Җәлилнең шәхси тормышы, иҗаты, батырлыгы турында бай мәгълүмат алырга була

В музее представлена богатая информация о личной жизни, творчестве, героизме Мусы Джалиля







«Алтынчәч» операсының либретто авторы буларак М.Җәлил исеме татар музыка сәнгатенә алтын хәрефләр белән язылды. Аның сүзләренә язылган җырлар мәңге җырланачак

Имя М. Джалиля, как автора либретто оперы «Алтынчәч», вписано в историю музыкального искусства золотыми буквами. Песни на его слова будут петь вечно

Музейның иң кадерле экспонаты – 1912 елда Италиянең Катания шәһәрендә ясалган мандолина. Муса уйнаган бу мандолинаны шагыйрьнең яшьлек дусты Мөбинә Таһирова бүләк итте

Самый ценный экспонат в музее – мандолина, которая была сделана в 1912 году в городе Катания Италии. Эту мандолину, на которой играл Муса, подарила подруга юности Мубина Тагирова







Җәлилнең каһарманлык юлларыннан эзтабарлар Новгород өлкәсенә – фронтовик-шагыйрь «Отвага» газетасы редакциясендә эшләгән, шуннан әсирлеккә төшкән «Үлем үзәне»нә барып җиттеләр

По героическим следам Джалиля следопыты добрались до Новгородской области – где поэт-фронтовик работал в редакции газеты «Отвага». Там, в «Долине смерти» он попал в плен




«Үлем үзәне»ннән кайткан экспонатлар

Экспонаты, привезенные из «Долины смерти»

М.Җәлилнең фашистлар тоткынлыгындагы чорын чагылдырган экспозиция

Тема экспозиции: «Муса Джалиль в фашистском плену»







Клич юного КОММУНАРА.

Орган Казанского Губернского Комитета Российского Коммунистического Союза Молодежи №1

СУББОТА, 25 ОКТЯБРЯ 1919 ГОДА.

Деникин — палач всех трудящихся хочет задушить Свободную Советскую Республику, надев на нее цепи царизма.

Красная молодежь! К оружию, к отпору врага, в последний и решительный бой!

Победим или умрем!

НАША ГАЗЕТА.

Җәлилнең туганнан туганы Таһир ага Корбанов «Клич юного коммунара» газетасының Муса тотып укыган санын бүләк итте

Двоюродный брат Джалиля Тагир Курбанов подарил тот самый экземпляр газеты «Клич юного коммунара», который читал Муса

Җәлилче-язучы Исхак Зәбировны Казан елга портында Карадуган мәктәбенең яшь җәлилчеләре каршы ала

Юные джалиловцы Карадуванской школы встречают писателя-джалиловеда Исхака Забирова в Казанском речном порту







Муса Җәлилнең бертуган сеңлесе Хәдичә апа белән очрашу истәлеге. Оренбург шәһәре, 1975 ел

Память о встрече с сестрой Мусы Джалиля Хадичей. г. Оренбург, 1975 г.

Музейда Муса Җәлилнең тоткынлыктагы көрәштәше Рушад Хисаметдинов белән очрашу. 1986 ел, февраль

Встреча в музее с соратником Мусы Джалиля в фашистской неволе Рушадом Хисамутдиновым. Февраль 1986 г.







Шагыйрьнең хатыны Әминә ханым һәм кызы Чулпан (беренче рәт, уртада), язучылар Гариф Ахунов (икенче рәт, сулдан өченче) һәм Рафаэль Мостафин белән очрашу. 1996 ел

Встреча с женой Аминой-ханум и дочерью Чулпан, с писателями Гарифом Ахуновым и Рафаэлем Мустафиным. 1996 г.

Җәлилче Фәрит Солтанбәков белән очрашу

Встреча с джалиловцем Фаридом Султанбековым





Муса Җәлил музееның 30 еллык юбилеена республиканың танылган язучылары, җәмәгать оешмалары вәкилләре, журналистлар, музей эшлекләре килде

На юбилей 30-летия музея Мусы Джалиля приехали знаменитые писатели, представители общественных организаций, журналисты и коллеги-«музейщики»

М.Җәлилнең туган көнендә «Кызыл ромашка» оешмасына тантаналы төстә яңа әгъзалар кабул итеәә

В день рождения М.Джалиля торжественно принимают юных членов в организацию «Красная ромашка»







СУГЫШЧАН ДАН ЗАЛЫ

1985 елда, Бөек Җиңүнең 40 еллыгына Сугышчан Дан залы ачылды. Бөек Ватан сугышы чоры тарихыбызда аерым урын алып тора. 1941–1945 еллар эчендә Арбаш, Карадуган, Таузар авылларыннан 365 кеше фронтка китә, шуларның 191е кире әйләнеп кайта алмый, яу кырында ятып кала... Тылда фидакарь хезмәт куючыларга да бу залда зур урын бирелгән. Сугышчан Дан залында авылдашларыбызның бөек көче, Ватанга мәхәббәте, җиңүне якынайтуга керткән чиксез зур өлеше чагыла.

ЗАЛ БОЕВОЙ СЛАВЫ

Зал Боевой Славы был открыт в 1985 году, в честь 40-летия Победы. Период Великой Отечественной войны занимает особое место в нашей истории. В 1941–1945 годах из деревень Арбаш, Карадуван, Тавзар на фронт отправились 365 человек, из них 191 не вернулись домой, пали в бою… В зале Боевой Славы отражается великая мощь односельчан, их любовь к Родине и огромная заслуга в победе над иноземными захватчиками. Не остались забытыми и самоотверженные работники тыла.



СЕБЕР ТРАКТЫ ТАРИХЫ МУЗЕЕ

Себер тракты тарихы музее 1995 елның 12 октябрендә ачылды. Аның нигезендә авыл тарихына кагылышлы эзләнүләр ята. Материаллар Карадуган авылы уртасыннан узучы Себер тракты дип аталган юлга да бәйле булу сәбәпле, экспозицияләрдә туган як һәм авыл тарихы гына яктыртылып калмыйча, Себер юлы турында да сөйләрлек мөмкинлек туды. Себер тракты Карадуган авылы аша Екатерина II идарә иткән (1762–1796) һәм шуннан соңгы елларда төзелә. Авылда зур почта станциясе, «пересыльный этап» – «Себер киткән» каторжаннарны йоклатып чыгаручы төрмә, казематлар булган.

Әлеге юлда күпләрнең язмышы очрашкан. 1790 елда А. Н. Радищев «Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт» исемле китабы өчен Себергә сөрелә. Ул Карадуганда 1790 елның 12–13 ноябрендә була, «Себергә сәяхәт» язмаларында безнең як авыллары турында да язып калдыра. Бу юл буйлап атаклы

МУЗЕЙ ИСТОРИИ СИБИРСКОГО ТРАКТА

Музей истории Сибирского тракта был открыт 12 октября 1995 года. В его основе лежат исследования, касающиеся истории села, однако богатый материал позволяет осветить и историю всего Сибирского тракта, проходящего через деревню Карадуван.

Сибирский тракт строился в годы царствования Екатерины II (1762–1796) и послеекатерининский период. В деревне работала почтовая станция, был пересыльный этап – тюрьма для ночевок каторжан, казематы.

Здесь пересекались судьбы разных людей. За «Путешествие из Петербурга в Москву» в 1790 году А. Н. Радищева ссылают в Сибирь. 12–13 ноября он проводит в Карадуване. А в записях «Путешествие в Сибирь» есть моменты, касающиеся деревень и сел нашего края. По этому пути проходили такие личности, как географ П. П. Семенов-Тян-Шанский, писатель Федор Достоевский, выдающийся татарский уче-





географ П.П. Семенов-Тян-Шанский, язучы Федор Достоевский, татар халкының күренекле галиме Шиһабетдин Мәрҗани, драматург, «Галиябану» драмасының авторы Мирхәйдәр Фәйзи дә узган. Себер трактына бәйле экспонатлар, фотографияләр, Казан губернасының карталары авыл өлкәннәре сөйләгән истәлекләр, риваятьләр Себер тракты образын күзалларга мөмкинлек бирә.

Почта бүлеге экспозициясендә 1907 елда авылда телеграф ачылу турындагы документны, Казан почта телеграф округының 1884 елгы

ный Шигабутдин Марджани, драматург, автор драмы «Галиябану» Мирхайдар Файзи. Экспонаты, фотографии, исторические памятники, карты Казанской губернии, народные предания, воспоминания старожилов позволяют представить образ Сибирского тракта.

Здесь можно увидеть документ 1907 года об открытии в селе телеграфа, карту Казанского почтово-телеграфного округа 1884 года, телеграфные аппараты, телефоны и даже «чайники» телеграфных столбов с изображением герба Российской империи.



картасын, телеграф аппаратлары, телефоннар, Россия империясенең герблы телеграф баганасы чәйнекләрен күрергә була.

Музейда татар байларына, сәүдәгәрләренә багышланган махсус бүлек тә бар. Экспозициядә данлыклы бай, химаяче Габдрахман Ишморатов турында бай мәгълүмат алырга, аның дебиторлык кенәгәсенең күчермәсе, сәүдә лицензиясе белән танышырга, Балтач бае Мортаза Мөлековка багышланган материаллар һәм документларны, Мортаза байның хезмәтчеләре белән төшкән фотосын күрергә була. Аның фабрикасында чуар салынган итекләр әүвәл Германиягә кадәр илтеп сатылган! Карадугандагы музей бинасы үзе дә – Мортаза Мөлеков милке. 1911 елда салынган бу йортның беренче катында хуҗа кибет тоткан, икенче каты мосафирханә булып торган. Музейда шундагы кунак бүлмәсенең интерьеры булдырылды, сату-сәүдә әсбаплары куелды. Революциядән соң бу бина почта, 1925 елдан мәктәп хезмәтен үтәде.

Мәчетләргә, мәдрәсәләргә багышланган бүлектә дини китаплар, гарәп шрифты белән язылган календарьлар, әдәби

В музее специальный отдел посвящен баям, торговцам и купцам. В экспозиции можно найти копию дебиторской книжки, торговую лицензию знаменитого мецената Габдрахмана Ишмуратова, документы и воспоминания, касающиеся Муртазы Мулюкова, бая из Балтасей, и даже фотографию, где он запечатлен в окружении своих слуг. В свое время его «пегие сапоги» (валенки) продавались даже в Германии! Само здание музея тоже бывшая собственность Муртазы Мулюкова. На первом этаже дома, построенного в 1911 году, хозяин держал магазин, второй этаж служил гостиницей. В музее восстановлен интерьер гостиной, выставлены на обозрение предметы торговли.

После революции этот дом служил почтовым отделением, а с 1925 года – школой.

Есть и отдел, посвященный духовенству нашего края, мечетям и медресе. Его содержание – религиозные книги, календари, набранные арабским шрифтом, литературные произведения, справки, переводы с французского языка, книги мулл с их собственными печатями. В том числе и «личные дела» последних.



әсәрләр, белешмәләр, француз теленнән тәрҗемәләр, муллаларның үз мөһерләре сугылган китапларын күрергә була. Шулай ук безнең як авыллары муллаларының «шәхси дело»лары да бар.

Карадуган авылының горурлыгы – урта мәктәп. Тарихын 1925 елдан башлап санаучы мәктәпкә тулы бер зал багышланган. Бу залда мәктәп ачылу турында документлар, беренче укытучыларның фотолары, Карадуган мәктәбендә укыган күренекле кешеләр турында мәгълүматлар, уку классы интерьеры, укытучыларның шәхси әйберләре урын алган.

Авылда колхоз төзелү, аның рәисләре, алдынгы колхозчылар турында аерым экспозиция сөйли. Монда революциядән соң оешкан кустарь-һөнәрчелек артельләре турында мәгълүматлар табарга була. Халыкның көнкүреш-куллану әйберләре дә экспозицияләрдә шулай ук зур урын алган. Музейда барлыгы 3 944 экспонат исәпләнә.

Гордость Карадувана – средняя школа. Школе, история которой началась в 1925 году, посвящен целый зал. В нем множество документов времен открытия школы, фотографии первых учителей, информация об известных выпускниках, интерьеры учебного класса, личные вещи преподавателей.

Отдельная экспозиция рассказывает о создании в деревне колхозов, о председателях и передовиках колхоза. Здесь можно получить богатую информацию о кустарно-ремесленных артелях, созданных после революции. А экспозиции, в которых собраны старинные предметы быта и орудия труда – особая гордость. В музее насчитывается 3 944 экспонатов.



ЦАРСТВОВАНІЕ ГОСУДАРЯ

ИМПЕРАТОРА АЛЕКСАНДРА I.

1817

27.006. — Августа 21. Высочайше утвержденное назначеніе этаповъ *для препровожденія арестантовъ по тракту отъ Москвы, чрезъ Казань и Пермь, по Тобольской Губерніи.*

Какихъ Губерній.	*Ночлеги и растахи.*	*Дни ночлеговъ и растаховъ.*	Число верстъ.	Гдѣ назначаются этапы и число дворовъ.	Изъ какихъ баталіоновъ и инвалидныхъ командъ и до какихъ пунктовъ препровождаются арестанты.
Казанской	Г. Казань	Вторникъ.	15	этапъ.	Изъ состоящаго тутъ гарнизоннаго полка и инвалидной команды препровождаютъ арестантовъ до с. Архангельскаго и до Свіяжска.
	Растахъ	Среда.			
	С. Рожественское	Четвертокъ.	19	55	
	С. Архангельское	Пятница.	16	этапъ.	Для содержанія сего этапа составляется вновь инвалидная команда въ штатномъ числѣ и препровождаетъ до Карадувана и до Казани.
	Растахъ	Суббота.		131	
	Г. Арскъ	Воскресенье.	23	75	
	Сельцо Казанбишъ	Понедѣльникъ.	18	8	
	Карадуванъ	Вторникъ.	15	этапъ.	Для содержанія сего этапа составляется вновь инвалидная команда въ штатномъ числѣ и препровождаетъ до Малмыжа и до села Архангельскаго.
	Растахъ	Среда.		23	
	Янгулово	Четвертокъ.	22	170	
Вятской	Г. Малмыжъ	Пятница.	23½	этапъ.	Какъ въ семъ городѣ вновь учреждающаяся уѣздная инвалидная команда еще не сформирована, то недостающее число нижнихъ чиновъ тотчасъ пополнить изъ Вятскаго баталіона, а Оберъ-Офицеровъ назначить изъ сверхъ-комплектныхъ Казанскаго полка, по несостоянію таковыхъ при Вятскомъ баталіонѣ. Сія команда препровождаетъ арестантовъ до большаго Килмесъ и до Карадувана.
	Растахъ	Суббота.		. .	
	Мелетъ	Воскресенье.	21½	37	
	Бол. Порекъ	Понедѣльникъ.	19	32	
	Б. Килмезъ	Вторникъ.	24	этапъ.	Для содержанія сего этапа составляется вновь инвалидная команда въ штатномъ числѣ и препровождаетъ до Сюмса-Можой и до Малмыжа.
	Растахъ	Среда.		45	
	Мукикакси	Четвертокъ.	26½	20	

Александр I патшаның 1817 ел, 21 август указы нигезендә арестантлар йөртү һәм этаплар (юл төрмәсе) тоту тәртибе күрсәтмәләре

На основании указа Александра I от 21 августа 1817 года, показания порядка передвижения арестантов и этапов (дорожной тюрьмы)

Казан губернасы Казан өязенең төньяк өлеше картасы. 1901 ел
Себер тракты ике параллель сызык белән күрсәтелгән

Карта северной части Казанского уезда Казанской губернии. 1901 г.
Сибирский тракт указан двумя параллельными линиями



По Сибирскому тракту

Карадуановский


по Московскому тракту

Этапъ 1-го разряда

Для


150 арестантов 1 офицера и 50 нижних чинов Этапной команды.

Фасадъ по линии С.Ю.



Планъ,

Составленный по распоряжению Комитета, Высочайше учрежденного






Карадуган этап төрмәсе проекты. 1840 ел

Проект этапной тюрьмы в Карадуване. 1840 г.

Этап төрмәсеннән калган кул богавы

Наручники – экспонат со времен этапной тюрьмы





Атлы почтага багышланган экспозиция

Экспозиция с атрибутами ямской почты







Почта станциясендәге мосафирлар йорты бүлмәсе

Гостиничная комната при почтовой станции

Юл кирәк-яраклары

Принадлежности путника







Тормыш-көнкүреш кул көченә корылган заманнарда кулланылган эш кораллары

Сельскохозяйственная утварь

Гөбе-май атлагыч

Маслобойка







Авыл халкының көнкүреш куллану әйберләре

Домашняя утварь





«Лавка» тотучының эш әсбаплары


Принадлежности лавочника

Авыл базары. XIX йөз ахыры

Базарный день. Конец XIX века







Балтач бае Мортаза Мөлеков (сулдан икенче) хезмәтчеләре белән

Купец Муртаза Мулюков (второй слева) со своими работниками



Казан артының атаклы бае Габдрахман Ишморатов

Знаменитый купец Заказанья Габдрахман Ишмуратов


Ишморатов бай товарлары рекламасы

Реклама товаров Ишмуратова

ТОРГОВЛЯ
Потомственнаго Почетнаго Гражданина
Абдрахмана Ахметовича
ИШМУРАТОВА.

ЧАЯМИ, САХАРОМЪ
ОПТОМЪ и въ РОЗНИЦУ.
Чай своей развѣски.
И МАНУФАКТУРНЫМИ ТОВАРАМИ,
частью изъ собствен. красильной фабрики.
Рысистый конный заводъ
чистой Орловской и Американской крови.
Лошади бѣгутъ на столичныхъ ипподромахъ съ большимъ успѣхомъ.
Заводъ находится въ 80-ти вер. отъ Казани, по Сибирскому тракту.
Адресъ: Казань, А. А. Ишмуратову.





Карадуган авылында метрика 1831 елдан алып барыла башлаган; димәк, мәчет тә шул вакытта салынган дип нәтиҗә ясап була. Музейда безнең якның диния тарихы, имамнарына аерым экспозиция багышланган

В Карадуване начали вести метрику с 1831 года. Можно предположить, что и мечеть была построена в это же время. Истории религии нашего края, духовенству посвящена отдельная экспозиция в музее

1897 елның 2 июлендә алынган 1516 номерлы указ нигезендә Карадуганда имамлык иткән Минһаҗетдин хәзрәт гаиләсе. Зәйнәп абыстай – кызлар мөгаллимәсе.
Минһаҗетдин хәзрәт 1936 елда кулга алына, төрмәдә вафат була

По указу №1516, выданному 2 июля 1897 года, в Карадуване духовным наставником стал Мингазетдин хазрат. Зайнап абыстай учила девочек.
В 1936 году Мингазетдин хазрат был арестован, умер в тюрьме





Шамаилләр, Коръән, намазлыклар – һәр өйдә кадердә булган

Шамаили, Коран, намазлык (коврик для молитвы) были в каждой мусульманской семье

Кулъязма Коръән


Рукописный Коран





Карадуган – патша заманнарыннан бирле почталы авыл.
Музейда почта хезмәтенең төрле чорларына караган экспонатлар бар.
Электрон почта әсбаплары


В музее собраны экспонаты, относящиеся к разным периодам почтовой службы.
Принадлежности электронной почты.



«Барышня» аша ялгаучы агач корпуслы телефон аппараты


Телефонный аппарат с деревянным корпусом, соединяющий через «Барышню»





1908 елда Карадуган авылында телеграф ачылуны раслаучы документлар. (Экспозиция)

Документы, подтверждающие открытие телеграфа в деревне Карадуван в 1908 г.



«Морзе «М-38» телеграф аппараты. XX йөз башы

Телеграфный аппарат «Морзе «М-38». Начало XX века

422261 Республика Татарстан,
Балтасинский муниципальный район,
д. Карадуван,
ул. Сибирский тракт, д. 49
Тел. 8 (84368) 3-21-09

Тираж 1000 экз. Заказ Е-334.

Отпечатано в полном соответствии с качеством
предоставленного электронного оригинал-макета в типографии
филиала ОАО «ТАТМЕДИА» «ПИК «Идел-Пресс».
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.